ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 9 Закона Республики Татарстан «О защите населения и территорий от чрезвычайных ситуаций»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 апреля 2020 года

**Статья 1**

Внести в статью 9 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 62-ЗРТ «О защите населения и территорий от чрезвычайных ситуаций» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 12 (II часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 11; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I часть); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 19 (часть I); 2020, № 4 (часть I) следующие изменения:

1) часть первую дополнить абзацами следующего содержания:

«установление обязательных для исполнения гражданами и организациями правил поведения при введении режима повышенной готовности или чрезвычайной ситуации в соответствии с абзацем вторым части первой статьи $8^1$ настоящего Закона;

с учетом особенностей чрезвычайной ситуации на территории Республики Татарстан или угрозы ее возникновения во исполнение правил поведения, установленных в соответствии с подпунктом «$а^2$» статьи 10 Федерального закона, установление при необходимости дополнительных обязательных для исполнения гражданами и организациями правил поведения при введении режима повышенной готовности или чрезвычайной ситуации в соответствии с подпунктом «$а^1$» статьи 10 Федерального закона.»;

2) часть вторую изложить в следующей редакции:

«Полномочия, указанные в абзацах втором – двадцать третьем части первой настоящей статьи, осуществляются непосредственно Кабинетом Министров Республики Татарстан или органом исполнительной власти Республики Татарстан,

специально уполномоченным на решение задач в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций. Полномочия, указанные в абзацах двадцать четвертом и двадцать пятом части первой настоящей статьи, осуществляются непосредственно Кабинетом Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
11 мая 2020 года
№ 24-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Законның $8^1$ статьясындагы беренче өлешенең икенче абзацы нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле тәртип кагыйдәләрен билгеләү;

Федераль законның 10 статьясындагы «а$^2$» пунктчасы нигезендә билгеләнгән тәртип кагыйдәләрен үтәү өчен, Татарстан Республикасы территориясендәге гадәттән тыш хәлнең үзенчәлекләрен яисә аның барлыкка килү куркынычын исәпкә алып, Федераль законның 10 статьясындагы «а$^1$» пунктчасы нигезендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гражданнар һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле өстәмә тәртип кагыйдәләрен, кирәк булган очракта, билгеләү.»;

2) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – егерме өченче абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләт тапшырылган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге

статьяның беренче өлешендәге егерме дүртенче һәм егерме бишенче абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 11 май
№ 24-ТРЗ